# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

«Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

1 статья. «Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 11) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләр федераль законнар, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән җайга салына.».

2. 4 статьяның 2 абзацын төшереп калдырырга.

3. 5 статьяның 7 абзацын төшереп калдырырга.

4. 12 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күрсәтелгән махсус рөхсәтләрне (лицензияләрне) биргән өчен җыем күләме федераль законнар нигезендә билгеләнә.».

5. 14 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Атмосфера һавасын пычрату лимитлары атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә идарәнең махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан, атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр ташлау белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар өчен, республикадагы экологик хәлне исәпкә алып, билгеләнгән нормативлардан чыгып, федераль законнар билгеләгән тәртиптә урнаштырылалар.».

6. 15 статьяда:

1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның атмосфера һавасына пычраткыч матдәләрне стационар чыганактан чыгарып ташлау процессы булган эшчәнлекләрен башкарулары, шулай ук атмосфера һавасына зарарлы физик йогынтының кайбер төрләрен ясаулары атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә идарәнең махсус

вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан федераль законнар билгеләгән тәртиптә бирелүче махсус рөхсәт (лицензия) нигезендә генә рөхсәт ителә.».

2 һәм 3 өлешләрне төшереп калдырырга.

7. 20 статьяның 3 өлешендә «әлеге Закон» сүзләрен «законнар» сүзенә алмаштырырга.

8. 22 статьяның 5 өлешен төшереп калдырырга.

9.30 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Атмосфера һавасын пычратуга бәйле эшчәнлекне чикләү, туктатып тору һәм тыю турындагы карарлар атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә идарәнең махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә кабул ителәләр.».

10. 32 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Атмосфера һавасының һәм аны пычрату чыганакларының торышы турындагы мәгълүматны җыю, саклау, эшкәртү һәм тапшыру Татарстан Республикасының әйләнә-тирә табигать мохите мониторингы буенча бердәм системасы кысаларында атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә идарәнең махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан, шулай ук башка махсус вәкаләтле органнар тарафыннан федераль законнар билгеләгән тәртиптә башкарыла.».

11. 34 статьяда:

1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт тикшереп торуы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, районнарның, шәһәрләрнең, шәһәрләрдәге районнарның җирле администрацияләре, атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану өлкәсендә идарәнең махсус вәкаләтле дәүләт органы, халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итү өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә башка махсус вәкаләтле органнар тарафыннан федераль законнар билгеләгән тәртиптә үз компетенцияләре чикләрендә башкарыла.»;

5 өлешне төшереп калдырырга.

<u>2 статья.</u> Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты
М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 22 феврале
№ 649